ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» октябрь 2023ел № 326

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча 2023 елның III-IV кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 10.02.2023 елның 35 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.11.2021 елның 1104 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлеге белән бәйле эксперт һәм консультацион ярдәм күрсәтү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2019 елның 888 номерлы “Татарстан Республикасы халыкка сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында” карар нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның III-IV кварталына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләп чыгару өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен 41 000 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәли көче 01.07.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р.М. Латыйпов**